**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**23 август, 2023 ел** **№ 314**

**Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» 2014 елның 31 мартындагы 350 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 349 карары белән расланган Биектау муниципаль районында вакантлы идарәче вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының иң югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турындагы нигезләмә нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы» МО МКУ Аппаратының кадрлар составы үзгәрү белән бәйле, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» 2014 елның 31 мартындагы 350 номерлы карары (30.03.2017 №128, 14.09.2018 №245, 22.05.2020 №373, 19.10.2020 №8, 01.03.2021 №57 карарлары редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составына үзгәрешләрне, 2 нче кушымтаны яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итеп кертергә.

2. Алга таба Биектау муниципаль районында вакантлы идарәче вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составына үзгәрешләр керткәндә, әлеге составны Биектау муниципаль районы Башлыгы карары белән расларга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» мәгълүмат сайтында https://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында https: //vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2023 елның 23 августында 214нче номерлы карары белән расланды

Биектау муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Афанасьев<br>Алексей Павлович | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы» МО МКУ аппараты җитәкчесе (алга таба - район Советы), комиссия рәисе; |
| Шакиров<br>Әнәс Шәүкәт улы | район башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Сабирова<br>Вероника Александровна | район Советының кадрлар бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |
| *Комиссия әгъзалары:* | |
| Денисова<br>Евгения Михайловна | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУнең (алга таба - район башкарма комитеты) гомуми бүлеге башлыгы; |
| Сабирова<br>Гүзәл Фәрит кызы | район башкарма комитетының эшләр идарәчесе; |
| Сабирова<br>Айгөл Илгиз кызы | район Советының юридик бүлеге башлыгы; |
| Сабирҗанов<br>Ринат Рәшит улы | район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Мөстәкыймова<br>Эльмира Фиргат кызы | район Советының оештыру бүлеге башлыгы; |
| Фәтхуллина<br>Юлия Геннадьевна | район Башлыгы ярдәмчесе (коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча). |